**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясепоселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**21.11.2023** **№ 1774**

# Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә уза торган муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 елның 18 мартындагы 330 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Биектау муниципаль районы территориясендә шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны җайга салу һәм идарә итү системасын оештыру һәм камилләштерү, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының билгеләнгән чикләрендә транспорт хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законына, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясына, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр, шул исәптән субсидияләр формасындагы грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында, һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карарына, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кадрлар үзгәрүгә бәйле рәвештә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә уза торган муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнарның

бер өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 елның 18 мартындагы 330 номерлы карарына (26.07.2023 №984 карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә уза торган автомобиль транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү буенча комиссия составыннан комиссия секретаре Нигъмәтуллина Айгөл Рәшит кызын, Биектау муниципаль районы башкарма комитеты икътисад бүлеге башлыгын чыгарырга. Комиссия составына Адиярова Ләйсән Хәйдәр кызын, Биектау муниципаль районы башкарма комитеты икътисад бүлеге баш белгечен кертергә

2. Әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесе урынбасары М.Р. Булгаковка йөкләргә.

Җитәкче Д.Ф.Шәйдуллин